Лиана. Күчкәнме бу залга дөньяның бар яме,
Күңелләр түрендә Әлифба бәйрәме .
Бу матур бәйрәмгә кушыл , дус , әйдәле ,
Дөньяны гөрләтсен Әлифба бәйрәме .

Даян.Над страной весенним утром
Занялась заря.
В школе праздник - светлый праздник,
Праздник «Букваря».

Заходите, проходите!
Путь свободен, освещен.
Приглашаем вместе с нами
Попрощаться с букварем!

Музыка астында 1 сыйныф укучылары класска керәләр.

Укытучы: Исәнмесез диеп сәлам юллыйм,
Һәрбер дәрес шулай башланган.
Хәзер үзегез белән танышаек-
Бәйрәмебез шулай каралган.

1. Мин **Элина**-тырыш кыз мин
Барысына да өлгерәм.
Җырлыйм,биим,дәресемне дә
Бик оста сөйләп бирәм.
2. Мин – **Алмаз,**
Шук малай,
Үткен малай.
Ут малай!
Мин – бик уңган!
Өлгер мин,
Юк-бар белән
Көлдермим!

3. Мин – **Диана.** Йолдызлыгым Кыз булыр,
Икенче көзне көтеп алсак миңа 8 яшь тулыр.
Менә хәзер сезнең алда чыгыш ясыймын бүген,
Җырлармын да, биермен дә,шигырь сөйләрмен димен.

4. Минем исемем**- Арсен.**
Апамнан калышмыйм диеп
Тырышам бар көчемә.
Тәртипле бул,күпне бел,-дип
Максат куйдым үземә.

5. Слак авылы матур авыл,

Мин шул авылда тудым!

Үз авылымнын батыр улы

Данил исемле булам!

6. Минем исемем – **Юлия.**
Таллар миңа баш ия.
Талга кунган сандугач
Син иң матур кыз дия.

7. Ә мин **Булат** булам.

Үзем тырыш, акыллы.

Тәртип тә бозмыйм болай.

Нәрсә әйтим инде сезгә -

Вообщем мин бик шәп малай .

Укуда да бик тырышам,

Спортны да яратам.

Ярышлар үткән чагында

Беренчелекне алам .

8. Минем исемем **Реана,**
Февраль аенда тудым мин.
Җырлыйм, биим, шигырь сөйлим,
Шундый уңган кыз бит мин.
9. Исемем минем **Данил.**
Йөземдә балкый гел нур.
Сөйләшергә яратам,
Барысын үземә каратам.
10.**Ильшат:** Мин гаиләдә кече малай
Булышам бөтен эштә.
Бик тырышам мәктәптә дә
Яхшы укырга теләп.

11.Минем исемем – **Артур.**

Русча дөрес,матур сөйлим

Яратам исәпләргә.

Матур-матур сүзләр өстәп

Әкиятләр сөйләргә.

12.Минем исемем **Алмаз.**

Гаиләдә мин бер генә

Яратам күп укырга

Башваткычлар чишәргә
Чиста,пөхтә язарга.

БЕРГӘ:

Әгәр ничәү дисәгез ?
Без класста 12.
Аерылмас дус булып
Тату булып үсәбез .

Укытучы:
Әле 1 нче сентябрь иртәсендә генә мәктәп бусагасын тәүге мәртәбә атлап кергән нәниләр бүген беренче җиңүләрен бәйрәм итәләр.Аларга хәрефләр тану,алардан иҗекләр,сүзләр төзү,укырга өйрәнү җиңел булмады.Тик алар югалып калмадылар, тырыштылар.Бүген сыйныфтагы һәр бала укый белә.Әлифба – баланың беренче уку китабы . Мәктәп бусагасын атлап кергәч тә ул туган телебез хәзинәсен шушы китап ярдәмендә өйрәнә башлый .
Балалар әлифбаны тәмамлап йомгак ясарга җыелдылар . Язнын бер матур көнендә алар бәйрәм итәләр . Әлифба сезне нәрсәләргә өйрәтте икән ? Сөйләп кәрсәтегез әле.

Уңган безнең балалар,
Шигырьләр күп беләләр.
Хәзер сезгә әйбәт итеп
Шуны сөйләп бирерләр.

1 нче укучы: Алтын яуган көзге көндә
Тыйнак үттек класска.
Әлифбаны кулга алдык
Әй,сөендек шул чакта.

2 нче укучы: Кичә әни белән бергә
Әзерләдек сумкамны.
Пеналыма тезеп куйдым
Карандаш һәм ручкамны.

3 нче укучы: Әтием дә , әнием дә
Бу көнне бик көттеләр.
Балалардай дулкынланып
Мине озата килделәр.

4 нче укучы: Тышта ап-ак кар яуганда
Без җыелдык бәйрәмгә.
Безнең шатлык эчкә сыймый

Сезгә ничек сөйләргә?

5 нче укучы: 39 хәреф белән
Таныштык без тиз генә.
Олы ярдәмчең булдың син
Рәхмәт инде Әлифба!

6 нчы укучы: Сәнгатьле итеп сөйләргә
Аңлаешлы укырга
Табышмаклар чишәргә,
Өйрәттең син Әлифба.

7 нче укучы: Кызларны ул зур ярдәмче,
Булышчы булсын диде.
Эшләгән һәрбер эшләре
Елмаеп торсын диде.

8 нче укучы: Ә малайларга Әлифба
Өйрәтте җитез булырга
Батыр ,кыю кешеләрдән
Үрнәк алып торырга.

9 нчы укучы: Өйрәтте Әлифба безне
Табигатьне сөяргә.
Кечкенә дусларыбызга
Бул син , дустым , дияргә.

10 нчы укучы:Курыкмаска салкыннан
Яңгыр,яшен,карыннан
Дус булсагыз , яратсагыз
Файда тияр барыннан.

11 нче укучы: Өйрәтте чиста булырга
Пөхтәлекне сакларга.
Усал , ямьсезләрдән безгә
Кечеләрне якларга .

Җыр “ Өйрәтәләр мәктәпләрдә”.

1. Каләм тотып кулларга
Хәрефләрне тезәргә
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.
Тапкырларга, бүләргә,
Нәниләрне сөяргә,
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.
2.Бишкә бишне кушарга
Иҗектән сүз ясарга.
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.
Белер өчен бик күпне.
Яратырга китапны
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.
3.Таңнар ничек атканын,
Кояш ничек батканын
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.

Табарга утрауларны.
Биек-биек тауларны
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.

Укытучы:
-Әнә Әлифбабыз үзе дә килеп җитте.

Әлифба: Мин Әлифба, таныйсызмы,
Танымыйм дип тормыйсызмы?
Юктыр, юктыр, ышанам,
Сезне күреп шатланам.
Исемдә һәрберебезнең
Күңелле йөзләрегез.
Яхшы дигәч, укытучыгыз,
Елмайды күзләрегез.
Хәзер инде зур кешеләр,
Балалар, булдыгыз сез.
Төрле-төрле китапларны
Яратып укырсыз сез.

Барысы бергә: Рәхмәт сиңа Әлифба.

Әлифба:

-Нәни дусларым, рәхмәт сезгә дә,
Әлифбаны нык үзләштергәнгә.
Белем сараен керергә ачып,
Сезнең кулларда хәзер бар ачкыч.
Нәни дусларым, шуны белегез:
Бары Әлифба белемгә нигез.
Зур доктормы ул, укытучымы,
Яки төзелештә бер инженермы,
Космонавтмы ул, әллә галимме,
Агроном яисә гади эшчеме,
Үтәргә эшнең кечесен-зурын,
Әлифбадан ул башлаган юлын.

Укытучы. Әйе. Белем үрләрен яулау бик җиңел булмады. Ләкин сез бик тырыштыгыз: укырга, язарга, матур итеп сөйләргә, хикәяләр төзергә, шигырьләр, табышмаклар, мәкальләр әйтергә, әдәпле булырга, өлкәннәрне һәм кечкенәләрне ихтирам итәргә, үзара дус – тату яшәргә, ирешкән уңышларга шатланырга, ярдәмчел булырга өйрәндегез.

Биремнәр:

1.Аз да түгел, күп тә түгел,
Утыз тугыз төп- төгәл.
Тәртип белән тезегез,
Рәттән әйтеп бирегез,
Аны белә һәр бала,
Бу рәт ни дип атала? (Алфавит)
Укучылар алфавитны чылбыр буенча әйтәләр.

Укытучы:Ә хәрефләр турында җыр да бармы?

Җыр “Алфавит”
Р.Зарипов көе, К. Нәҗми сүзләре

Алфавит бик кирәк нәрсә
һәммә кешегә.
Тик аны ятлау бик кыен
Без бит кечкенә.

Кушымта:
Алсу йөри урманда
Бөрлегән күп ди анда.
Вәсиләне Василий
Гөлҗимеш белән сыйлый.

Бер хикмәтле җыр бар икән
Апа өйрәтте.
Алфавит була дип
Ул әйтте.

Кушымта:
Алсу йөри урманда
Бөрлегән күп ди анда.
Вәсиләне Василий
Гөлҗимеш белән сыйлый.

Җырны мәгънәсез дисәгез
Әйдә көлегез.
Тик алфавит кирәк нәрсә
Шуны белегез.

Кушымта:
Алсу йөри урманда
Бөрлегән күп ди анда.
Вәсиләне Василий
Гөлҗимеш белән сыйлый.

Укытучы: Кем тапкыр, кем зирәк
Сынап карыйк әйдәгез.

Ш. Без табышмаклар әйтәбез
Сез җавабын табыгыз.

У.к. 1) Карурманда йөридер, кети-кети уйныйдыр. *(Шүрәле)*
2) Г.Тукай әкиятендә Шүрәленең бармагын кыстырган герой. *(Былтыр)*

Ш. 3) Һәркөн кирәк өстәлдә
Безгә куәт өстәргә *(Ипи)*
4) Җылы якларда яши,
Авыр йөкләр дә ташый. *(Фил)*

У.к. 5) Без-без безелдәп
Кортлар җыялар мине.
Салкын тиеп авыртканда
Дәвалыймын мин сине. *(Бал)*

Ш. 6) Син йоклагач, тәрәз артында
Елмаеп карый сиңа. *(Ай)*

Укытучы. Укучылар, сез чыннан да әлифбаны бик яхшы үзләштергәнсез. Әти-әниләрегез дә шулай тырышып укыдылармы икән! Әйдәгез, аларга берничә сорау биреп карыйк әле.

Әти-әниләргә сораулар.

Әлифбада сузык аваз хәрефләре нинди төс белән язылган?
Әлифбадагы бер шигырьне сөйләргә.
Әлифбада А дан соң нинди хәреф өйрәнелә?
Ф битендә нинди хайван рәсеме бар?

Данил:

Кушарга һәм алырга,
Кисемтәләр сызарга.
Күп нәрсәләргә өйрәндек
Математика дәресендә.

Бирем:
1. Керпе гөмбәгә барды,
9 ак гөмбә тапты.
3 не куйды энәсенә,
Калганын кәрзиненә.
Керпе ничә гөмбәне
Кәрзиненә куйды? (6)
2. 7 малай урамга
Чыкты футбол уйнарга.
Өчәү килде тагын да,
Исәплә син барын да.(10)
3. Ак каенда өч чыпчык,
Түбәдә биш сыерчык.
Әйтмәс микән берегез-
Барысы ничә кошчык?(8)
4.Айдар китте урманга,
Тәмле җиләк җыярга.
Менә 10 җиләк тапты,
Ничә калыр чиләктә?
5. Алмагачта 5 алма
Алар пешкән, алланган.
Берсен алды Әнисә
Агачта калды ничә?
6. Бер күлмәктә 3 төймә,
Бер күлмәктә 5 төймә.
3 төймә дә, 5 төймә,
Ничә? Шуны кем белә?

Артур:

Тезеләбез, бөгеләбез,
Шаярабыз, көләбез.
Физкультура – сәламәтлек,
Аны яхшы беләбез.

Күмәк бию.
На музыку Вступления дети выходят маршем и встают врассыпную.

1. Эй, лежебоки, ну-ка вставайте (дети выполняют марш на месте),
На зарядку выбегайте.
Хорошенько потянулись,
Наконец - то вы проснулись.
Начинаем, все готовы (стоя, руки – на поясе),
Отвечаем: «все готовы»! (дети поочередно отрывают от пола то правую, то левую пятку).
Начинаем, все здоровы, («разминка»).
Я не слышу?
Дети: «все здоровы»!
Становитесь по порядку (марш на месте)
На весёлую зарядку.
Приготовились, начнём
И все вместе подпоём.

Припев:
Солнышко лучистое любит скакать (дети ногами выполняют движение «разминка». Руками изображают солнышко, поднимая скрещенные руки вперед, затем опуская через стороны вниз и в конце фразы – два хлопка),
С облачка на облачко перелетать (ноги расставлены на ширину плеч. Руки, плавно качая вправо-влево, постепенно поднимаются вверх. В конце фразы – два хлопка поднятыми вверх руками).
Раз, два, три, четыре (дети выполняют двойные прыжки то на правой, то на левой ноге),
Раз, два, три, четыре, Раз, два, три, четыре… пять (руками выполняют взмахи, как «крылышками». На слово «пять» - прыжок (остановка), руки и ноги – в стороны. На паузу - еще один прыжок, но руки и ноги – вместе (точка).
2. Все разрабатываем руки (дети выполняют упражнение для рук: в стороны, к плечам, вверх, в стороны – 2 раза),
Нету места больше скуки.
Все разрабатываем плечи (поднимают и опускают плечи, держа руки чуть в стороны – 4 раза),
Чтоб в походах было легче.
Все разрабатываем ноги (руки – на поясе. Выставление правой, затем левой ноги на пятку – 2 раза),
Чтобы не уставать в дороге.
Все разрабатываем шею (руки – на поясе. Наклоны головы вправо - влево),
Чтобы пелось веселее (ноги – на ширине плеч).

Припев: Движения припева повторяются.

3. Так, приготовьтесь, сей момент (дети выполняют марш, стоя на месте),
Самый сложный элемент -
Надо пополам согнуться (расставляют ноги на ширину плеч)

И руками земли коснуться (наклоны туловища вперед, руками коснуться носочков ног и выпрямиться).
Ну-ка, ноги не сгибать,
Раз, два, три, четыре, пять (выполнить 4 наклона).
Молодцы все постарались (марш на месте),
Разогнулись, отдышались.

Припев.

4. Прыгают, скачут, все на свете (дети, двигаясь поскоками, перестраиваются в круг и продолжают движение по кругу),
Даже зайцы и медведи,
А жирафы и слоны,
Скачут прямо до луны.
Кошки, белки, лисы, свинки – (взявшись за руки, на поскоках – сужают круг)
Все на утренней разминке (расширяют круг).
Всем прибавилось настроение (снова сужают круг)
От такого пробуждения (расширяют круг).

Припев.

5. С чувством полного удовлетворения (легким семенящим бегом дети перестраиваются на свои места как в первоначальном построении),
В заключение упражнения -
Встали тихо на носочки (поднимаются на носки, тянуться вверх),
Тянем руки, что есть мочи (руки тоже поднимают вверх. Затем опускаются на всю ступню и опускают руки).
Прям до неба дотянись,
Выдыхаем ... руки вниз
Поздравляю, всё в порядке.
Молодцы,
Дети: «конец зарядке»!

Булат:
Технология дәресендә
Сувенирлар ясадык.
Кәгазьдән һәм картоннан,
Пластилин һәм мамыктан.

Әниләргә әзерләгән бүләкләрне бирәбез.

Диана:
Җыр дәресендә өйрәндек без
Бар дөньяның яме турында.
Бергәләшеп җырлау бик тә рәхәт
Магнитофон да булса яныңда.

“Кояшлы ил” җыры җырлана.

Кояшлы ил – безнең ил,
Күге аның гел аяз.
Кыш китерсә кыш бабай,

Чәчәк алып килә яз.

Һавасы да җире дә,
Салават күпере дә,
Яңгыры да, кары да –
Безгә якын бары да.

Сандугачлы урманы,
Ашлык тулы кырлары,
Бөтен җиргә яңгырый
Безнең бәхет җырлары

Әлифба:

- Рәхмәт, дусларым! Миңа сезнең белән саубуллашыргатвакыт җитте. Үземнең урынга тагын да акыллырак китапны – Туган телне калдырам. Хушыгыз, дусларым! Туган тел белән дус булыгыз, яхшы укыгыз, тату яшәгез.

Туган тел керә:

- Көттем мин бергәләп
Укыр көн җиткәнне
Мин әле өр-яңа
Бер тапсыз битләрем .
Килдем мин никадәр
Җыр, шигырь, хикәя
Мәкальләр күтәреп

-Хуш киләсез, кадерлеләрем! Минем янга килеп җитүегез белән котлыйм сезне. Мин сезгә яңа китаплар алып килдем, аларны бик яратып укыгыз, саклап тотыгыз. (“Туган тел” дәреслеклшреөләшә)

Укучылар:

1.Исәнме,китап!
Төшепбасмадан.
Синәлебердә,
Битеңачмаган.
2.Тышлыгыңматур,
Алакүзявын.
Каянтапканнар,
Шундыйбуявын?
3.Анамтеле–тугантелем,
Бикборынгычалтелем.
Көлепторгансөйкемлетел,
Бигрәктәмлебалтелем.
4.Яктыкиләчәклетелем,
Саф,пакътелем,байтелем.

Җаннарырыңныэретерлек,
Йомшаксарымайтелем.

Укытучы:

Кадерле туган телебез, балалар сиңа шигырь укып күрсәтергә, җырлар бүләк итәргә телиләр.

“Туган тел” җыры җырлана.

1. Балам диеп туган телдә
Эндәшә миңа әнкәм.
Әнием дипәнкәемә
Мин туган телдә өйтәм.

Кушымта: Дөньяда иң матур ил
Ул минем туган илем.
Дөньяда иң матур тел
Ул минем туган телем.

2. Туган телемдә сөйләшеп
Яшим мин туган илдә.
Туган тел дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.

3. Иң изге хисләремне мин
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам.

Юлия. Дөньяда иң матур ил
Ул минем туган илем.
Дөньяда иң матур тел
Ул минем туган телем

Тугантел:

-Һай, булдырдыгыз! Ана телебездә бигрәк матур сөйләшәсез икән. Мин сезне татар теленең матурлыгын, байлыгын, зирәклеген тагын да тирәнрәк күрсәтермен, шигырь, хикәяләрукытырмын.

Реана: Кая барма, урыс теле кирәк.
Без ул телне ныклап өйрәндек.
Дәресләрдә урыс телендә без
Күпме әкият, шигырь өйрәндек.

Учитель: А теперь, дорогие родители, ребята расскажут, как они учили русский язык.

ПЕРВЫЙ.

Ежедневно по утрам
Заниматься надо нам.

Мы с доски не сводим глаз,
И учитель учит нас.
Ель, топор, лопата, руки —
В каждом слове слышим звуки.
Звуки эти разные:
ВСЕ ВМЕСТЕ. Гласные, согласные.
ВТОРОЙ.
Гласные тянутся в песенке звонкой,
Могут заплакать и закричать,
В темном лесу звать и аукать,
И в колыбельке Аленку баюкать,
Но не желают свистеть и ворчать.
ТРЕТИЙ.
А согласные согласны
Шелестеть, шептать, скрипеть
Даже фыркать и шипеть,
Но не хочется им петь.
ВСЕ ВМЕСТЕ.
С-с-с… змеиный слышен свист,
Ш-ш-ш… шуршит опавший лист.
Ж-ж-ж… шмели в саду жужжат,
Р-р-р… моторы тарахтят.
ЧЕТВЕРТЫЙ.
Дружат гласная с согласной,
Составляя вместе слог.
МА и ША (запомни: МАША!)
К нам явились на урок.
ПЯТЫЙ.
Если слоги встанут рядом,
Получаются слова.
ТЫ и КВА, а вместе ТЫКВА,
СО и ВА, читай: СОВА.
ШЕСТОЙ.
К букве – буква, к слову – слово:
Родилась родная речь!
СЕДЬМОЙ.
Соединили мы два слова —
И предложение готово:
Дождь идет.
Гремит гроза.
Улетела стрекоза.
ОДНА ГРУППА. Мы изучили буквы, слоги.
ВСЕ ВМЕСТЕ. И научились все читать.
ВТОРАЯ ГРУППА. Открыты школьные дороги
ВСЕ ВМЕСТЕ. Для любознательных ребят.
ВСЕ ВМЕСТЕ. Спасибо букварю!

(**Звучит торжественная музыка и входит Букварь)**

Букварь: Вот и я, мои друзья!
Рад вам, рад вам очень я!
Приятно слышать добрые слова о себе.

Я – Букварь, учу читать,
Меня никак нельзя не знать.
Меня изучишь хорошо –
И сможешь ты тогда
Любую книжку прочитать
Без всякого труда!
Я приготовил для вас задания. Если со всеми справитесь, то получите от меня подарок!
(Букварь передаёт учителю конверт с заданиями)

Ведущий: Ребята, трудностей не боимся? Тогда принимаемся за задания!

1.Игра на внимание **«Это я, это я, это все мои друзья»**. Ребята, я сейчас буду задавать вопросы, а вы дружно, хлопая в ладоши, отвечайте: «Это я, это я, это все мои друзья». Или вы топаете ногами, отвечаете: «Нет, не я, нет, не я, и не все мои друзья»! Давайте, потренируемся! Итак, начинаем!

Кто ватагою весёлой каждый день шагает в школу?
Это я…
Кто из вас приходит в класс с опозданием на час?
Нет, не я...
Кто домашний свой урок выполняет точно в срок?
Это я…
Кто из вас хранит в порядке книжки, ручки и тетрадки?
Это я…
Кто из вас, скажите вслух, на уроке ловит мух?
Нет, не я..
Кто из вас, скажите хором, занят в классе разговором?
Нет, не я…
Кто из вас, узнать хочу, забияка и драчун?
Нет, не я…
Кто из вас такой ловкач, лучше всех играет в мяч?
Это я …
Кто из вас не ходит хмурый, любит спорт и физкультуру?
Это я…
Кто из вас своим трудом украшает класс и дом?
Это я ..
Есть ребята среди вас, кто маме помогает каждый раз?
Это я…
Кто из вас из малышей ходит грязный до ушей?
Нет, не я…
Кто из вас сюда принёс красивый танец7?
Это я…
Сейчас мы это проверим!

Танец с зонтиками.

Солнышко сияло в небе голубом,
Тучка налетела, и раздался гром,
Зонтики мы взяли и пошли гулять,

Капельки под дождиком считать

Пр. Дождик капает здесь тихий
Кап –кап –кап!
Я ступаю тихо – тихо,
Кап –кап –кап!
Суетливый, непослушный
Кап –кап –кап!
Я гуляю, ох по лужам,
Кап –кап –кап!

Капли с неба льются, облачку привет!
Поливает дождик целый белый свет!
Село наш красавец дождиком умыт,
Осень золотая к нам спешит

2.Все дети – большие любители сказок! А теперь, когда вы познакомились со всеми буквами русского языка, вы сможете сами перечитать любимые сказки. Угадайте сказочного героя. Я называю первую часть имени, а вы вторую. Отвечаем хором.
Курочка ….
Карабас ….
Вини ….
Иван …..
Иван …
Царевна …
Емеля ….
Мальчик ….
Красная ….
Баба …
Кощей ….
Елена ….

Укытучы:

Кадерле балалар! Безнең Әлифбаны өйрәнүдә зур көчләрен куючылар - әти-әниләребез Әйдәгез аларга рәхмәтебезне белдерик .

1нче укучы:
Сезгә зур рәхмәтебезне
Җиткерәбез Һәммәбез

Олы ярдәмегез өчен
Башыбызны иябез.
2 нче укучы:
Әткәй - әнкәй , газизләрем
Гомер биргәнсез безгә
Изге итеп үстердегез
Мең рәхмәтлемен сезгә .

3 нче укучы:
Сезнең алда сүз бирәбез
Тырыш булырга
Ялкауланмаска. ;
Артта калмаска.
"2" ле алмаска.
4 нче укучы:
Укырбыз "5" кә
Вәгъдәне үтәрбез
Теләккә җитәрбез
Туган илгә хезмәт итәрбез.

Укытучы: Быел без бик күп нәрсәләр белдек, ә өйрәнәселәр алда тагы да күбрәк. Ләкин мин ышанам: белем юлындагы авырлыкларны без бергәләп җиңәрбез, чөнки һәрвакытта сезнең белән янәшә әти – әниләрегез, туганнарыгыз. Алар сезнең шатлыкларыгызны да, борчуларыгызны да уртаклашалар, ягымлы карашлары, йомшак җылы куллары белән сезне иркәлиләр, сөяләр, сезгә акыллы киңәшләрен бирәләр.

(Ишектән атылып-бәрелеп 1 малай керә)
-Әй, нишлисез сез монда? Нәрсәгә дип барыгыз да җыелдыгыз?
Укытучы: Абау кем бу? Нинди тәртипсез малай бу? Ишек шаку юк, исәнләшү юк, атылып, бәрелеп килде дә керде, әллә нинди ямьсез сүзләр сөйли башлады. (Малай кызларның чәчләрен тарта)
Башлангыч сыйныф укучысыдыр әле син бәлки? Әле дәресләрен дә хәзерләп йөрми торгандыр?
Малай: Мин укучы түгел , ләкин укучы булсам да өй эшләрен эшләмәс идем.
Сез дә эшләмәгез.Нәрсәгә ул өй эшләре. Рәхәтләнеп уйнагыз.
Укытучы: Абау, кем соң син малай,ә?Безнең балаларны әшәкелеккә өйрәтеп йөрисең бит син.
Малай: Танымыйсызмы?Белмәсәгез, белегез.(Кофтасын сала, анда "2"ле дигән язу килеп чыга.) "2" ле булам мин! Сезнең янда калырга килдем.

Мин нәрсә әйтим сезгә, балалар?
Берни белмим мин – авыр минем хәл.
Укыйсы килми, язасы килми,
Өй эшләрен дә үтисе килми.
Уйнап йөрим мин гел эштән качып,
Ә ашаганда кирәк зур кашык.
Укытучы: Ә менә ни өчен шундый тәртипсез икәнсең син. Балалар, сезнең арада андыйлар юкмы?
Бал-р: Юк, юк.

Малай: Димәк, без сине кабул итмибез. Бар, кит.
(“2” лене куып чыгаралар)
(Ишектән “2”лене бәреп ега язып “3” ле керә)

- Гафу итегез, ишекне шакып керергә онытканмын. Нинди бәйрәм сездә?

Укытучы: Бездә Әлифба бәйрәме, “3” ле. Әле син тагын 1 нәрсәне оныттың, исеңә төшер әле .

-Нәрсәне?Ә,ә,ә гафу итегез.Исәнмесез.

Укучылар: Исәнмесез “3”ле.

-Мин дә “4” ле белән янәшә барам,
Ләкин “2”гә тәгәрәп барам.
Әгәр бар көчем биреп тырышсам,
Мин дә “4” легә тиңләшә алам.
Укытучы:
-Балалар, “3” лене алабызмы?
Балалар:
-Юк. (“3” читкә китә.)
(*Бергәләп киңәшкәннән соң бик теләмиче генә “3” лене алып калалар)*
(Ишектә “4”ле)
-Исәнмесез! Әлифбаны өйрәнеп бетергәнсез дип ишеткән идем.Бәйрәм итәсезмени?

Укытучы: Әйе шул “4”ле Синдә кал безнең бәйрәмебездә.

-Ярар, дусларым.Мин сирәк-мирәк булса да онытылгалап куям шул.

-Мин дә “5”ле белән гел янәшә йөрим, һәр эшнең яхшы булуын телим.
Укытучы:
-Балалар, “4” лене алабызмы?
Балалар:
-Әйе.

Укытучы: Балалар, безгә кунакка кем килми калды соң әле?

Укучылар: Без “5” лене көтәбез.

“5” ле керә:
-Исәнмесез, саумысез,
Минем нәни дусларым.
Кемнәр авырлыктан качмый,
Яратам мин шуларны.
Кемнәр тырышып укый,
Дөрес һәм матур яза,
Тәртипле һәм эштә җитез,
Шулар минем дусларым.
Укытучы:
-Балалар, “5” лене алабызмы?
Балалар:
-Әйе.
“5”ле укучылар арасына кереп баса.

Укытучы:
-Балалар, сез киләчәктә нинди булырсыз?
Балалар:
-Яхшы укырбыз, яхшы билгеләр алырбыз, сүзне тыңларбыз, тәртипле булырбыз.

Укытучы. Кадерле кунаклар, бәйрәмебезнең беренче өлеше тәмам. Хәзер концерт номерлары тәкъдим итәбез.

Бәйрәм ахырында 1 сыйныф укучыларын әти-әниләре, мәктәп дирекциясе котлый. Балаларга истәлекле бүләкләр бирелә. Кичә чәй табыны артында дәвам ителә.

Максат: тырышып укуның кирәклеген исбатлау; күп белергә омтылучанлык, китапка мәхәббәт тәрбияләү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен, укучыларның сәләтләрен үстерү.

Җиһалау: интерактив такта, плакатлар, төсле кәгазьләрдән киселгән билгеләр һәм хәрефләр.

Кулланылган әдәбият исемлеге:

1. Иң матур сүз.Уку китабы.Казан: “Мәгариф”,2000.
2. Балалар әдәбияты.Хрестоматия. Казан: “Мәгариф”,2004